**СОВЕТ АЛЕКСАНДРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**422613 н.п. им. «25 Октября»**
**тел: 8-(84378) -3-54-22**
**факс: 8-(84378) -3-54-22**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛЕКСАНДР АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**422613 н.п. им. «25 Октября»**
**тел: 8-(84378) -3-54-22**
**факс: 8-(84378) -3-54-22**

**2025 елның 04 сентябре** **41 номер**

**КАРАР**

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Александр авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 12 декабрендәге 73 номерлы Александр авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 24 июнендәге 158-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Александр авыл җирлеге советы карар чыгарды**:**

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Александр авыл җирлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау хакында»2022 елның 12 декабрендәге 73 номерлы Александр авыл җирлеге карарына үзгәрешләр кертергә:

1) **27 статьяның 3 пунктындагы 3 абзацында** «һәм гамәлгә ашырганда» сүзләрен " дәүләт (муниципаль) ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны үзәкләштерү нәтиҗәсендә бюджет акчаларын экономияләү барлыкка килгәч һәм гамәлгә ашырганда" сүзләренә алмаштырырга.;

**2) 28 статьяның 2 өлешендә** «составын һәм срокларын» сүзләрен «төзү тәртибен, составын һәм срокларын һәм» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Александр авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Александр җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисадый үсеш комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Александр**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **Гогонов А.А.**